ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.04.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1443**

Җиңү көнен бәйрәм итүгә бәйле рәвештә Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) бер тапкыр бирелә торган түләүләр оештыру турында

Бөек Җиңү көнен бәйрәм итү уңаеннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) финанс ярдәм күрсәтү максатларында, 2026 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында ассигнованиеләр каралган буенча Зеленодольск муниципаль районы Советының «2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» 2025 елның 13 декабрендәге 34 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә җирлекләр буенча теркәлгән Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын (тол ирләрен), шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге вафат булган гражданнарның исемлекләрен 25.01.2026 елдан алып 25.04.2026 елга кадәр Зеленодольск муниципаль район Башкарма комитетына тапшырырга тәкъдим итәргә.
2. 2026 елга Зеленодольск муниципаль районының расланган бюджеты чикләрендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән түләүгә чыгымнарны, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ финанслауны тәэмин итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә 09.05.2026 кадәр бер кешегә түләү ведомостьлары нигезендә 2000,00 (ике мең) сум күләмендә түләүләр башкарырга.
4. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә) бер тапкыр бирелә торган түләүләрне тапшыруны оештыруда Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре Башлыклары һәм ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Рәхәт» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге ДАУСО тарафыннан ЗМР Башкарма комитетына ярдәм итүне тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының

җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында бастырып чыгарыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин